**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3682**
**30.07.2020**

Башкарма комитетның аерым карарларына
үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020 елның иң яхшы дворнигы» исеменә шәһәр конкурсын үткәрү турында» 2020 елның 22 маендагы 2403 номерлы карары белән расланган «2020 елның иң яхшы дворнигы» исеменә шәһәр конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), эш стажы;»;

2) 18 пунктка түбәндәге редакциядә икенче абзац өстәргә:

«Шәһәр конкурс комиссиясенең фактта катнашучы әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.».

2. Башкарма комитетның 2020 елның 22 маендагы 2404 номерлы карары белән расланган «2020 елның иң яхшы яшелләндерүчесе» шәһәр һөнәри осталык конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), эш стажы;»;

2) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Комиссия карары буенча югарыда саналган барлык эш төрләрен яки аларның берсен үткәрү һәм бәяләү гамәлгә ашырыла, әмма конкурсның барлык катнашучылары өчен эшләр саны бер үк булырга тиеш.»;

3) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Комиссия карары 2020 елның 12 августында беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.».

3. Башкарма комитетның 2020 елның 22 маендагы 2405 номерлы карары белән расланган «2020 елның иң яхшы сантехнигы» шәһәр һөнәри осталык конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), эш стажы;»;

2) 18 пунктка түбәндәге редакциядә икенче абзац өстәргә:

«Шәһәр конкурс комиссиясенең фактта катнашучы әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.».

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов